КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 7 март г.Казань № 127

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спорт әзерлеге буенча өстәмә мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләрне билгеләү турында» 2019 ел, 31 октябрь, 979 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спорт әзерлеге буенча өстәмә мәгариф программалары гамәлгә ашырыла торган физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләрне билгеләү турында» 2019 ел, 31 октябрь, 979 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 14 декабрь, 1134 нче; 2021 ел, 18 ноябрь, 1234 нче; 2023 ел, 10 октябрь, 1291 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның өченче абзацында «20 000» саннарын «100 000» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан башкарыла, спорт әзерлеге буенча өстәмә мәгариф программалары гамәлгә ашырыла торган физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибенең 1 пунктындагы өченче абзацында «20 000» саннарын «100 000» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Спорт әзерлеге буенча өстәмә мәгариф программалары гамәлгә ашырыла торган муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләрне

гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 8 пунктындагы җиденче абзацында «20 000» саннарын «100 000» саннарына алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин